СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

“ 02” ноябрь 2023ел — №1-27

Концессион килешүне башка шартларда төзү мөмкинлеге турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы $4^{8}$ өлеше, «Концессион килешү төзү өчен конкурста катнашуга әзерлек турында гариза формасын раслау һәм концессион килешү төзү инициативасы белән чыгыш ясаучы зат белән концессион килешү төзү турында тәкъдим формасына үзгәрешләр кертү хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 16.09.2023 елның 16 сентябрендәге 1515 номерлы карары, «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тубән Шүләңгер авыл җирлеге муниципаль милкендә булган су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү турындагы тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тубән Шүләңгер авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең концессион килешү төзү инициаторы тәкъдим иткән башка шартларда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тубән Шүләңгер авыл җирлеге муниципаль милкендә булган су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү мөмкинлеге турында Карар кабул итәргә.
2. Әлеге карарга теркәлеп килүче Концессион килешү шартларын башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә килештерү максатларында сөйләшүләр уздыру тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга. (1 нче кушымта)
3. «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем төзергә һәм аның кушымта итеп бирелә торган составын расларга.
4. Күрсәтелгән эшче төркемгә әлеге карарга кул куйган көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә концессион килешү шартларын тикшерү һәм аларны Тәртип нигезендә килештерү максатларында «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр формасында

сөйләшүләр уздырырга. 5. Башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында «Торак пунктларга хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә хәбәр итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советының 2023 елның 20 июнендәге № 3-24 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.михайловага йөкләргә.

9. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /Е.М.Михайлова/

Республика Татарстан Муниципальное образование «Нижнешандерское сельское поселение» Мамадышского муниципального района
СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1626001059